УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Ахтямова, дом 14,
город Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ
Әхтәмов урамы, 14 нче йорт,
Казан шәһәре, 420021

Тел./ факс: (843) 293-14-89, zags@tatar.ru, zags.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**Казан шәһәре**

**«30» сентябрь 2020 ел.** **№ 44**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең 2013 елның 17 декабрендәге 144 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан апостиль бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 16 маендагы 395 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең (алга таба – Идарә) «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан апостиль бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 17 декабрендәге 144 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең 2016 елның 28 сентябрендәге 62 номерлы, 2018 елның 19 июнендәге 35 номерлы, 2018 елның 24 октябрендәге 85 номерлы, 2019 елның 29 октябрендәге 82 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан

апостиль бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Идарә биналарындагы мәгълүмат стендларында һәм Идарәнең рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында булган мәгълүматларны үз эченә ала»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Идарәнең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.5 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);»;

җиденче абзацта «210-ФЗ номерлы федераль законның» сүзләрен «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктта «Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил рәсми документларын легальләштерү таләбен гамәлдән чыгара торган Конвенциянең 5 статьясы (1961 елның 5 октябрендә Гаагада төзелгән) (Россия өчен 1992 елның 31 маенда гамәлгә кергән) (чит ил рәсми документларын легальләштерү таләбен гамәлдән чыгара торган Конвенция Статусы белән берлектә (2006 елның 16 гыйнварына) (алга таба – Гаага конвенциясе); «Гражданлык хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы федераль законның 13 статьясы (алга таба – 143-ФЗ номерлы федераль закон); Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе мәсьәләләре» 2007 елның 7 ноябрендәге 614 номерлы карары (алга таба – Идарә турында нигезләмә)»;

2.4 пунктта «Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе территориясеннән читкә чыгарылырга тиешле Россия рәсми документларында апостиль кую турында» 2015 елның 28 ноябрендәге 330-ФЗ

номерлы федераль законның (алга таба – 330-ФЗ номерлы федераль закон) 6 статьясы; 210-ФЗ номерлы федераль законның 7.2 статьясының 3 пункты»;

2.6 пунктта «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма»;

2.8 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында «Россия Федерациясе Салым кодексы» сүзләреннән соң «(алга таба – РФ Салым кодексы)» сүзләрен өстәргә;

2.14 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы визуаль һәм текстлы мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы булган урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Идарә бүлмәләрендә әлеге Регламентның 1.3.5 пунктында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, объектлардан һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла, түбәндәгеләрне дә кертеп:-

объектларга һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалана алу шартлары;

объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль рәвештә яки хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр ярдәмендә хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

объектларга керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итә алу функциясе нык бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм объектларда аларга ярдәм күрсәтү;

инвалидларның объектлардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

хезмәттән файдалану өчен кирәкле, тавыш ярдәмендә һәм күрсәтмә мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм Брайль рельеф-нокта шрифтлары белән һәм контраст фонында башкарылган текстлы һәм графиклы башка

мәгълүматны кабатлап күрсәтү, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене, шулай ук ишарә телен белә торган башка затны кертү;

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль законның 15 статьясының 7 пункты нигезендә, махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, озата йөрүче этне объектка кертү;

хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга алар өчен үтемле формада хезмәт күрсәтү тәртибен аңлатуга, аны күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүгә, инвалидларны кабинетларның урнаштырылу тәртибе белән таныштуыруга, хезмәттән файдалану өчен кирәкле гамәлләр эзлеклелегенә бәйле кирәкле ярдәмне күрсәтү;

күрү буенча инвалидлар өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Идарәнең рәсми сайтыннан файдалана алу шартлары;

хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәттән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны үтүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү.

2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.»;

«Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «880 номерлы карар» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идарә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе».

**Идарә башлыгы**
**вазыйфаларын башкаручы** **Р.Х. Әхмәтҗанов**